**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

с. Якушкино

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноября 2022 года №1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ

1. 2022 елның 24 ноябрендә 09.00 сәгать 00 минутка Якушкино авылы Гагарин урамы 2А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Якушкино торак пунктында Гагарин, Дорожная, К.Маркс, Ленин урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 25 ноябрендә 09.00 сәгать 00 минутка Якушкино авылы Гагарин урамы 2А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Якушкино торак пунктында Мәскәү, Яр буе, Кыр, Мәктәп урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Якушкино авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Якушкино авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2023 елда һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Якушкино авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

Якушкино авылында һәйкәлне ремонтлау

Якушкино авылында мәдәният һәм ял паркы төзү».

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Хәмидуллин